ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

13.10.2022 | с. Старое Русское Маматкозино | 02

"Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында гражданнардан үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча граждannар җыенын билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, 56 ст., "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 25 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылында гражданнардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Татар Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәлен реконструкцияләү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Татар Мәмәтхуҗасы авылы, Кояшлы урамы, 20 йорт адресы буенча Саттарова Н.А. йорты янында гражданнар җыенын 10.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкама комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В.В.Никитушкин